| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.05.2021 57

Баулы муниципаль районы Советының «Өченче затлар хокукларыннан азат һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга, индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга бирү өчен каралган муниципаль мөлкәтне арендага бирү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2017 елның 15 декабрендәге 138 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 23 декабрендәге 976 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге, өченче затлар хокукыннан азат (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен каралган мөлкәт исемлегенә кертелгән дәүләт мөлкәтен арендага бирү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 25 мартындагы 170 номерлы карары нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Советының «Өченче затлар хокукларыннан азат һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга, индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым

режимын кулланучы физик затларга муниципаль мөлкәтне арендага бирү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2017 елның 15 декабрендәге 138 номерлы карарына (2021 елның 7 апрелендәге 48 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1нче кушымтадагы Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы милкендәге, өченче зат хокукларыннан азат (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга, индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм махсус салым режимын кулланучы физик затларга бирү өчен каралган мөлкәтне милек исемлегенә кертелгән милекне арендага бирү тәртибенә һәм шартларына:

9 нчы пунктта «җир кишәрлегеннән файдаланган өчен» сүзләреннән соң «күчемсез мөлкәт объекты астында» сүзләрен өстәргә;

10 нчы пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Мөлкәтне арендалауда ташлама кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы, мөлкәтне арендалаучы һәм социаль әһәмиятле эшчәнлек төрләре, Россия Федерациясенең билгеләнгән башка дәүләт программалары (ярдәмче программалары), Татарстан Республикасының дәүләт программалары (ярдәмче программалары), эшчәнлекнең өстенлекле төрләре муниципаль программалары (ярдәмче программалары) белән шөгыльләнүче физик затларга бирелә. Күрсәтелгән ташлама түбәндәге зурлыктагы аренда түләвен билгеләүдән гыйбарәт:»;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кече һәм урта эшкуарлык субъекты, индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар белән төзелгән мөлкәтне арендалау шартнамәсен вакытыннан алда өзгәндә, әлеге Тәртипнең 10 пунктында каралган шартларда, арендатор әлеге Тәртипнең 10 пунктында каралган милекне арендалау шартнамәсе буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яисә арендатор әлеге Тәртипнең 10 пунктында каралган критерийларга

туры килмәгән очракта, килешүне төзү хокукына торглар нәтиҗәләре буенча аренда шартнамәсендә билгеләнгән аренда бәясе муниципаль мөлкәттән файдалануның барлык срогы өчен 100 процент күләмендә түләнергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советының икътисадый үсеш, эшкуарлык, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе Р.Х. Гатиятуллин